**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары,**
**Бөтендөнья татар конгрессының**
**Милли Шура рәисе**
**В.Г. ШӘЙХРАЗЫЕВ**

**РАСЛЫЙМ:** ________________

**№** ______ 1 апрель 2026 **ел.**

## Татарстаннан читтә эшләүче татар телле массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре һәм журналистлары, интернет-ресурслары арасында IV бөтенроссия “ХӘБӘР” конкурсы турында НИГЕЗЛӘМӘ

### 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия регионнарында нәшер ителүче татар телле гәҗитләр, эфирга чыгучы татар телле теле- һәм радиотапшырулар редакцияләре һәм журналистлары, шулай ук интернет-сайтлар һәм “Вконтакте” социаль челтәрендәге төркемнәр арасында IV бөтенроссия “Хәбәр” конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Конкурсның оештыручысы – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты (алга таба – Оештыручы).

1.3. Конкурс 2026 елның 1 апреленнән 2026 елның 1 октябренә кадәр үткәрелә. Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Оештыручыларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://tatar-congress.org/ru) «Яңалыклар» бүлегендә урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта номинацияләр, конкурс эшләрен бәяләү критерийлары, конкурска гаризалар кабул ителә башлау һәм тәгәлләнү сроклары, урыны күрсәтелә.

### 2.Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс Татарстаннан читтә нәшер ителүче татар телле гәҗитләрнең, эфирга чыгучы теле- һәм радиотапшырулар редакцияләренең һәм журналистларының, интернет-сайтларның һәм “Вконтакте” социаль челтәрендәге төркемнәрнең (алга таба – Катнашучы) татар телен һәм милли кыйммәтләрне пропагандалауга, татарлар тормышын һәм эшчәнлеген, шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты эшчәнлеген яктыртуга

багышланган аеруча әһәмиятле эшләрен барлау һәм бүләкләү максатыннан уздырыла.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

- татар халкының телен, тарихи мирасын, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен пропагандалау, Россия регионнарындагы татар телле журналистларны барлау;
- татар халкының мәдәниятенә һәм тарихына, танылган шәхесләренә игътибар арттыру;
- иҗади багланышларны арттыру һәм ныгыту, журналистларның һөнәри, иҗади үсешен һәм осталыгын арттыру өчен үзара тәҗрибә уртаклашу һәм фикер алмашу;

## 3. Конкурска гариза бирүчеләр һәм конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Россия регионнарындагы татар телле гәҗит һәм теле- һәм радиотапшырулар редакцияләре, редакцияләрнең авторлары, авторлар коллективлары, интернет-сайт һәм “Вконтакте” челтәрендәге төркемнәрнең хуҗалары яисә рәсми вәкилләре катнаша.

3.2. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә.

3.3. Гариза бирүчеләр конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм шартларда документлар әзерләргә һәм тапшырырга тиеш.

3.4. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

3.5. Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта конкурс комиссиясе тарафыннан карала торган документлар һәрбер номинация буенча аерым әзерләнергә тиеш.

## 4. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

4.1. Конкурска гаризалар 2026 елның 1 апреленнән кабул ителә башлый. Конкурска гаризалар кабул итү 2026 елның 1октябрендә тәгәлләнә. Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат Бөтендөнья татар конгрессының рәсми сайтында 2026 елның ноябрь аенда урнаштырылачак.

4.2. Конкурста катнашу өчен 2025 елның ноябреннән 2026 елның сентябренә кадәр татар телендә дөнья күргән эшләр кабул ителә.

4.3. Оештыручы түбәндәге документлар теркәлгән гариза кабул итә:

а) конкурс эшләре, 2 дән 5кә кадәр (алга таба – конкурс эше):

- телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы) MP4, AVI, MOV форматында кабул ителәләр. Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә редакция мөһере (булган очракта) һәм җитәкче имзасы белән таныкланган булырга тиеш;
- радиоэшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы) MP3 форматында кабул ителәләр. Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә редакция мөһере (булган очракта) һәм җитәкче имзасы белән таныкланган булырга тиеш;
- басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы мәкаләләр (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар) пдф варианта кабул ителә. Язмалар редакция мөһере (булган очракта) һәм җитәкче имзасы белән таныкланган булырга тиеш;
- интернет-ресурслар. Катнашучы интернет-ресурска актив сылтама күрсәтергә тиеш. «ВКонтакте» социаль челтәрендәге төркем һәм интернет-сайт 2025 елдан да соңга калмыйча төзелгән булуы шарт. «ВКонтакте» төркемендә кимендә 1000 язылучы булырга тиеш.

б) Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада күрсәтелгән рәвештә анкета (1 нче кушымта);

в) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

- юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);
- юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);
- гамәлгә кую документлары, устав (электрон күчермәсе);
- ММЧ теркәү турында таныклык күчермәсе, йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

г) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

- ММЧ теркәү турында таныклык күчермәсе, йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;
- баш мөхәррирне вазыйфага билгеләп кую турында документ (күчермәсе)

д) авторлар, авторлар коллективлары өчен:

- шәхесне таныклаучы документ (паспорт күчермәсе);
- хезмәткәрнең редакция таныклыгы күчермәсе, яки хезмәткәрнең редакциядә эшләвен, яки редакция белән хезммәттәшлек итүен раслаучы баш мөхәррир тарафыннан имзаланган белешмә;
- персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга ризалык бирү (2 нче кушымта нигезендә);

е) интернет-сайтлар һәм «ВКонтакте» төркемнәре хуҗалары һәм рәсми вәкилләре өчен:

- шәхесне таныклаучы документ (паспорт күчермәсе);
- сайтлар өчен. Сайтка булган хокукларны раслау. Идарә панеленең (мәсәлән, WordPress, Joomla, хостинг) күренеп торган домен белән скриншотын ясау. DNS-язма аша хокукларны раслау (доменга TXT-язма өстәргә сорарга мөмкин). Әгәр сайт Tilda, Wix һ.б. конструкторда ясалган булса, төзәтү мөмкинлеге булган аккаунттан ясалган скриншот;
- •«ВКонтакте» төркеменә булган хокукларны раслау: администраторның (гариза бирүченең) ID күренеп торган "төркем белән идарә итү" бүлегенең скриншоты. Әгәр бергәлек бизнес-аккаунтка бәйләнгән булса төркемнең хуҗасыннан раслау скриншоты;
- персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга ризалык бирү (2 нче кушымта нигезендә).

Барлык документлар PDF форматта, электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.4.Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми.

4.5.Гаризалар Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге электрон почта аша кабул ителә: kheber_vkt@mail.ru. Электрон хатка документлар һәм конкурс эшләре (интернет-ресурслар сылтамалары) беркетелгән булырга тиеш.

Белешмәләр өчен Телефон: 8 (843) 236-49-66.

4.6. Документларның Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетына килгән көне аларны тапшыру датасы дип санала.

4.7. Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- гаризаның әлеге Нигезләмәнең 4.2., 4.3. пунктларында каралган таләпләргә туры килмәве яисә гаризага әлеге Нигезләмәнең 4.3. пунктында күрсәтелгән документларны теркәмәү;
- гаризаны билгеләнгән срокны бозып тапшыру.

4.8. Конкурска йомгак конкурс комиссиясе тарафыннан 2026 елның ноябрь аеннан соңга калмыйча ясала. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү турында Оештыручының рәсми сайтында өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

4.9. Конкурсны оештыручылар эшләрне, шул исәптән бүләкләргә лаек булган эшләрне дә киләчәктә файдалануны күздә тотмый, шуңа бәйле рәвештә конкурста катнашучылар эшләрне киләчәктә ничек файдал ануны мөстәкыйль хәл итә. Бу авторга иҗади эштән үзе теләгәнчә файдаланырга, аерым алганда, килешү төзерлек зат яисә оешма табу мөмкинлеген бирә.

4.10. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (командировка һ.б.) Гариза бирүче/Катнашучы тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

## 5. Конкурсның номинацияләре

5.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

**«Г.Тукай тууына 140 ел»** (әлеге номинациягә Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы тарафыннан игълан ителгән «Тукай елы» уңаеннан бөек шагыйрьнең тормышы һәм иҗатына багышланган материаллар кабул ителә);

**«Безнең батырлар»** (әлеге номинациягә Махсус хәрби операциядә катнашучы татар егет-кызларына багышланган материаллар кабул ителә);

**«Иң яхшы интернет-ресурс»** (татар телле интернет-сайтлар һәм «Вконтакте» төркемнәре арасыннан сайлана. Интернет-ресурсның бер еллык эшчәнлеге бәяләнә).

## 6. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

6.1. Конкурс эшләрен бәяләгәндә түбәндәге критерийлар кулланыла:

- конкурс эшләренең Конкурс максатларына һәм бурычларына туры килүе (0-5 балл);
- тапшырылган эшләрнең актуаль, объектив һәм тикшерелгән, аналитик яктан тирән булуы (0-5 балл);
- тәрбияви һәм иҗтимагый кыйммәте, авторның гражданлык позициясе чагылу (0-5 балл);
- эшнең югары һөнәри дәрәҗәдә эшләнүе (адресат тарафыннан җиңел кабул ителү, тел-сурәтләү чаралары куллану, композиция-структура төзелешенең югары сыйфатлы дизайны һәм бизәлеше) (0-5 балл);
- тапшырылган эшләрнең матур әдәби телдә булуы (0-5 балл);
- концепциянең, сценарийның, теманың, теманы яктыртуның кабатланмаган булуы,шәхси иҗат стиле булу (0-5 балл).

## 7. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

7.1. Конкурс комиссиясенең составы Конкурсны оештыручы тарафыннан раслана, 5 әгъзадан тора, аларга рәис, рәис урынбасары һәм әгъзалар керә.

7.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

7.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип таныла.

7.4. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның тарафыннан билгеләнгән урынбасарына йөкләнә.

7.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлар нигезендә бәяли. Һәрбер критерий буенча балларның саны 5 баллы шкала (0 – 5 балл) буенча бәяләнә.

Һәрбер гариза буенча баллар саны, конкурс комиссиясе әгъзалары куйган бәядән чыгып, уртача баллны исәпләү юлы белән чыгарыла.

7.6. Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип таныла һәм акчалар билгеләнгән башка җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

7.7. Һәрбер критерий буенча җыелган баллар суммасыннан чыгып, катнашучыларның рейтингы төзелә. Рейтингта 1 – 3 урын алган катнашучылар җиңүче дип игълан ителә. Баллар тигез булганда Конкурс комиссиясе әгъзалары карары нигезендә призлы урыннар ике яисә берничә җиңүчегә бирелергә мөмкин, бу очракта әлеге призлы урынга тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында тигез өлешләп бүленә.

7.8. Номинациядә премия яулаган конкурс эше берничә авторныкы, иҗат коллективыныкы, берничә массакүләм мәгълүмат чарасыныкы булса, акча эшне башкаруда катнашкан затларга, алар үзләре килешенгән күләмдә, Оештыручы тарафыннан бүлеп тапшырыла. Мондый килешү документлар белән бергә тапшырыла.

7.9. Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

7.10. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

7.11. Конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

7.12. Конкурс йомгаклары беркетмәгә имза салынганнан соң өч календарь көн эчендә Оештыручының рәсми сайтларына урнаштырыла.

## 8. Финанслау

8.1. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан финанслана.

8.2. Гомуми приз фонды – 550 000 сум.

8.3. Конкурста җиңүчеләр чәчәкләр, дипломнар һәм акчалата премияләр белән түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| № | Номинацияләр | Премияләр саны | Премия суммасы (мең сум) | Гомуми сумма (мең сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | **«Г.Тукай тууына 140 ел»** | 3 | 75 | 225,0 |
| 2. | **«Безнең батырлар»** | 3 | 75 | 225,0 |
| 3 | **«Иң яхшы интернет-ресурс»** | 2 | 50 | 100,0 |
| Барлыгы | | | | 550,0 |

8.4. Юридик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 3 көн дәвамында, җиңүчеләрне бүләкләгәннән соң, Оештыручы җитәкчелегенә язылган рәсми хатта күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

8.5. Физик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 3 көн дәвамында, җиңүчеләрне бүләкләгәннән соң, Оештыручы җитәкчелегенә язылган рәсми хатта күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

## 9.Аерым шартлар

9.1. Оештыручы түбәндәгеләргә хокуклы:
әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;
эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Оештыручыларның рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

9.2. Конкурс шартлары үзгәрү турында хәбәрнамә алганнан соң, Конкурста катнашучы эшләрне элек билгеләнгән шартларда кабул итүне яисә кертелгән үзгәрешләрне гамәлдә түгел дип тануны таләп итә алмый. Аның эшне Конкурсның яңа шартларына туры китереп үзгәртүе алга таба конкурста катнашырга мөмкинлек бирә.